**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге**

---

**КАРАР**
**09.08.2023 ел**

**КАРАР**
**№80**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 6 февралендәге 16091815201700011 номерлы хокукый экспертиза нәтиҗәсе, Сарман районы прокуратурасының 2023 елның 22 февралендәге 02-07-01 номерлы протесты, Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Иске Имән авыл җирлеге Советының 2022 елның 16 декабрендәге 65 номерлы «Иске Имән авыл җирлеге Советының "җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибе турында" 2017 елның 12 июнендәге 54 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова